ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ АКТАНЫШБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423740, Актанышбаш авылы,
Мәктәп ур., 19 йорт

СОВЕТ АКТАНЫШБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423740, д. Актанышбаш,
ул. Школьная, дом 19

**Постановление** — **КАРАР**

**3 марта 2025 года** — **№ 3**

**Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлегенең
Чөгәнә авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Актаныш муниципаль районының «Актанышбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә:

КАРАР ИТЭМ:

1. 2025 елның 13 мартында 18 сәгать 00 минутка Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлегенең 2024 елның 25 декабрендәге 31 номерлы «Чөгәнә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлегенең 2024 елның 25 декабрендәге 31 номерлы «Чөгәнә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы карарының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертү белән килешәсезме:
"Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 130 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 70 граждан кертелде.
Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлар түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен 70 граждан тавыш бирде;
«Каршы» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.
«Тыелып калдылар» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Чөгәнә авылы, Колхоз урамы 47 йорт;

4. Халык җыенын оештыручы итеп Актаныш муниципаль районының Актанышбаш авыл башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга, Актанышбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Актаныш муниципаль районы**

**Актанышбаш авыл җирлеге Советы рәисе** **Х.М.Хакимов**

ОГРН 1021605558
СОВЕТ
АКТАНЫШБАШСКОГО
сельского поселения
ИНН 1604001351